КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 ноябрь

г.Казань

№ 1187

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипне раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1173 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипкә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипне раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1173 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 июнь, 499 нчы; 2017 ел, 9 октябрь, 772 нче; 2020 ел, 16 май, 394 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипкә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. План, әгәр бюджет турындагы закон бер финанс елына расланган булса, чираттагы финанс елына яки, әгәр бюджет турындагы закон чираттагы финанс елына һәм план чорына расланган булса, чираттагы финанс елына һәм план чорына төзелергә һәм расланырга тиеш.

Яңа төзелгән учреждениенең планы агымдагы финанс елына һәм план чорына төзелә.

Учреждение тарафыннан шартнамәләр (контрактлар) шартлары буенча үтәү срогы бу пунктның беренче абзацында каралган сроктан артып киткән йөкләмәләр кабул ителгәндә, гамәлгә куючы орган карары буенча План күрсәткечләре әлеге сроктан артып киткән чорга раслана.»;

7 пунктның 2 пунктчасында:

беренче абзацта татар текстында «түләүләрнең» сүзеннән соң «(алдагы хисап чорларында учреждение тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләрнең үтәлеше буенча түләүләрне кертеп)» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлекчәсе булган учреждение, бүлекчәләрне исәпкә алмыйча төзелгән баш учреждение планы һәм, баш учреждение белән бүлекчә арасындагы исәп-хисапларны исәпкә-алмыйча, Бүлекчә планы нигезендә Учреждение планын төзи.»;

8 пунктта:

«а» пунктчасында:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«узган хисап чорларында учреждениеләр тарафыннан башкарылган түләүләрне кире кайтарудан (шул исәптән агымдагы финанс елында учреждениенең кредит оешмасы тарафыннан алынмаган түләүләрне; салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентларның артык түләнгән суммаларын, учреждение тарафыннан бирелгән кредитларны (заемнарны, ссудаларны) кире кайтаруга бәйле рәвештә) (узган елның дебитор бурычы) – бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары классификациясенең бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары төренең аналитик төркеме коды буенча;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«депозитларда элек урнаштырылган акчаны кире кайтарудан – бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары классификациясенең бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары төренең аналитик төркеме коды буенча;»;

«б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, физик һәм юридик затларга ссудалар, кредитлар күчерү буенча – бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары классификациясенең бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары төренең аналитик төркеме коды буенча;»;

«в» пунктчасында «аерымланган бүлекчә(-ләр)» сүзләрен «бүлекчә» сүзенә алмаштырырга;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Түләүләр буенча план күрсәткечләре, аларга үзгәрешләр кертелгәннән соң, агымдагы финанс елы башына акчаның калган өлешен исәпкә алып, план керемнәре күләменнән артып китә алмый.»;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агымдагы финанс елы түләүләренең план күрсәткечләре нигезләүләре (исәп-хисаплары), учреждение тарафыннан еллык бухгалтерлык хисабы төзелгәннән һәм расланганнан соң, агымдагы финанс елы башына кабул ителгән һәм үтәлмәгән

йөкләмәләр күләме өлешендә төгәлләштерелергә тиеш.»;

15 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чираттагы финанс елында һәм тиешле план чоры елында керемнәрнең күрсәткечләренә, хисап чоры белән чагыштырганда, 20 проценттан артык үзгәреш кертелгән очракта, гамәлгә куючы органга әлеге үзгәрешләрне кертү сәбәпләре турында мәгълүмат җибәрелә.»;

39 пунктта:

беренче абзацта «төзергә планлаштырыла торган контрактлар (шартнамәләр)» сүзләрен «планлаштырыла торган түләүләр» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «һәм муниципаль ихтыяҗларны» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 17 сентябрендәге 932 номерлы карары белән расланган Товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алу планын формалаштыру кагыйдәләренең 4 пункты нигезләмәләре нигезендә сатып алулар планына кертелми торган сатып алулар күрсәткечләренә» сүзләрен өстәргә;

41 пунктта:

«тиешле Россия Федерациясе Хөкүмәте,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Россия Федерациясе субъекты», «җирле администрация» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

43 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт бюджет учреждениесе планы түбәндәгеләр тарафыннан раслана:

гамәлгә куючы органының карары нигезендә башка раслау тәртибе билгеләнмәгән булса, учреждениенең вәкаләтле заты (бу пунктның алтынчы абзацында каралган очрактан тыш);

бухгалтерлык хисаплылыгының Планны раслау (Планга үзгәрешләр кертү) датасына кадәрге соңгы хисап датасына учреждениенең вакытында түләнмәгән кредит бурычы булган очракта, гамәлгә куючы органның вәкаләтле заты.»;

44 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлекчәсе булган учреждение, бу Үрнәк тәртипнең 43 пункты нигезендә расланган План нигезендә, бүлекчәне исәпкә алмыйча, Учреждение планын һәм һәр бүлекчә өчен учреждение белән бүлекчә арасындагы исәп-хисаплар күрсәткечләрен үз эченә алган Планны раслый.»;

кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипкә кушымта

Форма

РАСЛЫЙМ

______________________________________
(вәкаләтле зат вазифасы исеме)

______________________________________
(гамәлгә куючының (учреждениенең) исеме)

____________ ______________________
(имзасы) (имзаны таркатып язу)

20__ ел, «__» ________

20 _____ елга ( 20 _____ елга, 20 ____ һәм 20 _______ еллар план чорына[1]) финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы

| | | Код-лары |
|---|---|---|
| 20__ ел, «_____» _____________[2] | Дата | |
| Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган _______________ | Җыелма реестр буенча | |
| | БК буенча бүлек | |
| | Җыелма реестр буенча | |
| | ИНН | |
| Учреждение ___________________________________ | КПП | |
| Үлчәү берәмлеге: сум | ОКЕИ буенча | 383 |

1 бүлек. Керемнәр һәм түләүләр

| Күрсәткеч исеме | Юл коды | Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча коды[3] | Аналитик коды[4] | Суммасы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 20___ елга (агымдагы финанс елына) | 20___ елга (план чорының беренче елына) | 20____ елга (план чорының икенче елына) | план чорын үткәннән соң |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Агымдагы финанс елы башына акчаның калган өлеше[5] | 0001 | х | х | | | | |
| Агымдагы финанс елы ахырына акчаның калган өлеше[5] | 0002 | х | х | | | | |
| Керемнәр – барысы | 1000 | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| милектән керемнәр – барысы | 1100 | 120 | | | | | |
| шул исәптән: | 1110 | | | | | | |
| учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләрдән, эшләр башкарудан, чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр – барысы | 1200 | 130 | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| учреждениене төзегән гавами-хокукый оешмасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр | 1210 | 130 | | | | | |
| Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр | 1220 | 130 | | | | | |
| штрафлардан, пенялардан, мәҗбүри алуның башка сумаларыннан керемнәр – барысы | 1300 | 140 | | | | | |
| шул исәптән: | 1310 | 140 | | | | | |
| кире кайтарылмый торган акчалата | 1400 | 150 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| керемнәр – барысы | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| максатчан субсидияләр | 1410 | 150 | | | | | |
| капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр | 1420 | 150 | | | | | |
| башка керемнәр – барысы | 1500 | 180 | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| активлар белән операцияләрдән керемнәр – барысы | 1900 | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| башка керемнәр – барысы[6] | 1980 | х | | | | | |
| шулардан:<br>узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтару исәбенә акчаның калган өлешен арттыру | 1981 | 510 | | | | | х |
| Чыгымнар – барысы | 2000 | х | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| персонал өчен түләүгә – барысы | 2100 | х | | | | | х |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| хезмәт өчен түләү | 2110 | 111 | | | | | х |
| персоналга башка түләүләр, шул исәптән компенсация характерындагы түләүләр | 2120 | 112 | | | | | х |
| аерым вәкаләтләрне үтәү өчен башка түләүләр (учреждениенең хезмәт өчен түләү фондыннан тыш) | 2130 | 113 | | | | | х |
| хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә мәҗбүри социаль иминләштерү кертемнәре һәм учреждение хезмәткәрләренә башка түләүләр – барысы | 2140 | 119 | | | | | х |
| шул исәптән: | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә | 2141 | 119 | | | | | х |
| хезмәткәрләргә башка түләүләргә | 2142 | 119 | | | | | х |
| хәрби хезмәткәрләр-нең һәм махсус исемнәре булган хезмәткәрләрнең акчалата тәэминаты | 2150 | 131 | | | | | х |
| хәрби хезмәткәрләр-гә һәм махсус исем-нәре булган хезмәт-кәрләргә акча тәэ-минаты күләменә бәйле түләү чыгым-нары | 2160 | 133 | | | | | х |
| хәрби хезмәткәрләр-гә һәм махсус исем-нәре булган хезмәт-кәрләргә башка тү-ләүләр | 2170 | 134 | | | | | х |
| персоналга иминият кертемнәре салы-нырга тиешле түләү-ләр өлешендә мәҗ-бүри социаль имин-ләштерүгә иминият кертемнәре | 2180 | 139 | | | | | х |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| стажерларның хез-мәте өчен түләүгә | 2181 | 139 | | | | | х |
| халыкка социаль һәм башка түләүләр – барысы | 2200 | 300 | | | | | х |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| гражданнарга со-циаль түләүләр (га-вами норматив со-циаль түләүләрдән башка) | 2210 | 320 | | | | | х |
| шулардан: гражданнарга посо-биеләр, компенса-цияләр һәм башка социаль түләүләр (гавами норматив йөкләмәләрдән баш-ка) | 2211 | 321 | | | | | х |
| стипендияләр түләү, белем алучыларга стипендия фонды акчасы исәбеннән | 2220 | 340 | | | | | х |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| социаль ярдәм күрсәтү башка чыгымнарны гамәлгә ашыру | | | | | | | |
| мәдәният, сәнгать, мәгариф, фән һәм техника өлкәсендәге казанышлар өчен физик затларга премия бирү, шулай ук фән, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә проектларга ярдәм күрсәтү максаты белән грантлар бирүгә | 2230 | 350 | | | | | х |
| халыкка башка түләүләр | 2240 | 360 | | | | | х |
| салымнар, җыемнар һәм башка түләүләрне түләү – барысы | 2300 | 850 | | | | | х |
| шулардан:<br>оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы | 2310 | 851 | | | | | х |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка (чыгымнар составына керә торган) салымнар, шулай ук дәүләт пошлинасы | 2320 | 852 | | | | | х |
| штрафлар (шул исәптән административ), пенялар, башка түләүләр түләү | 2330 | 853 | | | | | х |
| оешмаларга һәм физик затларга кире кайтарылмый торган акча күчерү – барысы | 2400 | х | | | | | х |
| шулардан:<br>бюджет учреждениеләренә бирелә торган грантлар | 2410 | 613 | | | | | |
| автоном учреждениеләргә бирелә торган грантлар | 2420 | 623 | | | | | |
| коммерциягә карамаган башка оешмаларга (бюджет һәм | 2430 | 634 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| автоном учреждениеләрдән тыш) бирелә торган грантлар | | | | | | | |
| шулардан:<br>башка оешмаларга һәм физик затларга бирелә торган грантлар | 2440 | 810 | | | | | х |
| халыкара оешмаларга кертемнәр | 2450 | 862 | | | | | х |
| чит ил дәүләтләре хөкүмәтләре һәм халыкара оешмалар белән килешүләрне тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында түләүләр | 2460 | 863 | | | | | х |
| башка түләүләр (товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга түләүләрдән башка) | 2500 | х | | | | | х |
| учреждение эшчәнлеге нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплау буенча Россия Федерациясе суд актларын һәм бөтендөнья килешүләрен үтәү | 2520 | 831 | | | | | х |
| товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу чыгымнары – барысы[7] | 2600 | х | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр сатып алуга | 2610 | 241 | | | | | |
| дәүләт мөлкәтен капиталь ремонтлау максатларында товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга | 2630 | 243 | | | | | |
| башка товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга | 2640 | 244 | | | | | |
| дәүләт мәгълүмат системаларын | 2650 | 246 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| булдыру, үстерү, эксплуатацияләү һәм эксплуатациядән чыгару максатларында товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга | | | | | | | |
| энергетика ресурсларын сатып алуга | 2660 | 247 | | | | | |
| дәүләт милке объектларына капитал салулар, барысы | 2700 | 400 | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| дәүләт учреждениеләре тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу | 2710 | 406 | | | | | |
| дәүләт учреждениеләре тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын төзү (реконструкцияләү) | 2720 | 407 | | | | | |
| махсус чыгымнар | 2800 | 880 | | | | | |
| Керемне киметә торган түләүләр, – барысы[8] | 3000 | 100 | | | | | х |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| табышка салым[8] | 3010 | | | | | | х |
| өстәлгән кыйммәткә салым[8] | 3020 | | | | | | х |
| керемне киметә торган башка салымнар[8] | 3030 | | | | | | х |
| Башка түләүләр – барысы[9] | 4000 | х | | | | | х |
| шулардан:<br>субсидия акчасын бюджетка кире кайтару | 4010 | 610 | | | | | х |

2 бүлек. Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга түләүләр буенча белешмә[10]

| Күрсәткеч исеме | Юл коды | Сатып ала башлау елы | Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча коды[10.1] | Уникаль коды[10.2] | Суммасы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 20____елга (агымдагы финанс елына) | 20___ елга (план чорының беренче елына) | 20____ елга (план чорының икенче елына) | план чорын үткәннән соң |
| 1 | 2 | 3 | 3.1 | 3.2 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга түләүләр – барысы[11] | 26000 | x | | | | | | |
| шул исәптән: «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 223-ФЗ номерлы Федераль закон) нормаларын кулланмыйча, агымдагы финанс елы башына кадәр төзелгән контрактлар (шарт- | 26100 | x | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 3.1 | 3.2 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| намәләр) буенча[12] | | | | | | | | |
| 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 223-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын кулланмыйча, тиешле финанс елында төзергә планлаштырыла торган контрактлар (шартнамәләр) буенча[12] | 26200 | x | | | | | | |
| 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 223-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, агымдагы финанс елы башына кадәр төзелгән контрактлар (шартнамәләр) буенча[13] | 26300 | x | | | | | | |
| шул исәптән: 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә | 26310 | x | x | | | | | |
| шулардан[10.1] | 26310.1 | | | | | | | |
| шулардан[10.2] | 26310.2 | | | | | | | |
| 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә | 26320 | x | x | | | | | |
| 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 223-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, тиешле финанс елында төзергә планлаштырыла торган контрактлар (шартнамәләр) буенча[13] | 26400 | x | | | | | | |
| шул исәптән: дәүләт биремен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә җирелә тор- | 26410 | x | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 3.1 | 3.2 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ган субсидияләр исәбеннән | | | | | | | | |
| шул исәптән: 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә | 26411 | х | | | | | | |
| 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә[14] | 26412 | х | | | | | | |
| Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә бирелә торган субсидияләр исәбеннән | 26420 | х | | | | | | |
| шул исәптән: 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә | 26421 | х | | | | | | |
| шулардан[10.1] | 26421.1 | х | | | | | | |
| 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә[14] | 26422 | х | | | | | | |
| капиталь салуларны гамәлгә ашыруга бирелә торган субсидияләр исәбеннән[15] | 26430 | х | | | | | | |
| шулардан[10.1] | 26430.1 | х | | | | | | |
| шулардан[10.2] | 26430.2 | | | | | | | |
| мәҗбүри медицина иминияте акчасы исәбеннән | 26440 | х | | | | | | |
| шул исәптән: 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә | 26441 | х | | | | | | |
| 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә[14] | 26442 | х | | | | | | |
| финанс тәэминатының башка чыганаклары исәбеннән | 26450 | х | | | | | | |
| шул исәптән: 185-ФЗ номерлы Федераль закон | 26451 | х | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 3.1 | 3.2 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| нигезендә | | | | | | | | |
| шулардан[10.1] | 26451.1 | х | | | | | | |
| шулардан[10.2] | 26451.2 | | | | | | | |
| 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә | 26452 | х | | | | | | |
| Тиешле сатып алу елы буенча тиешле финанс елында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзергә планлаштырыла торган контрактлар буенча барлыгы | 26500 | х | | | | | | |
| шул исәптән сатып алу башлану елы буенча | 26510 | | | | | | | |
| Тиешле сатып алу елы буенча тиешле финанс елында 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзергә планлаштырыла торган шартнамәләр буенча барлыгы | 26600 | х | | | | | | |
| шул исәптән сатып алу башлану елы буенча | 26610 | | | | | | | |

Учреждение җитәкчесе
(учреждениенең вәкаләтлее заты) __________ __________ ______________________
(вазифасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Үтәүче _________ _________________________ ______________________
(вазифасы) (фамилиясе, инициаллары) (телефон)

20__ ел, «__» ___________

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ

______________________________________________________________________________
(гамәлгә куючының вәкаләтле заты вазифасы исеме)

______________________________ ______________________________________________
(имзасы) (имзаны таркатып язу)

20__ ел, «__» _________

---------------------------------------

[1]Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы закон расланган очракта.

[2]Финанс-хуҗалык эшчәнлеге планына (алга таба – План) кул кую датасы, ә План учреждениенең вәкаләтле заты тарафыннан расланган очракта Планны раслау датасы күрсәтелә.

[3]3 графе түбәндәгеләр чагылдырыла:

1100 – 1900 юллар буенча – бюджетлар керемнәре классификациясе бюджетлары керемнәре төркемчәсенең аналитик төркеме кодлары;

1980 – 1990 юллар буенча – бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары классификациясенең бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары төрләренең аналитик төркеме кодлары;

2000 – 2800 юллар буенча – бюджетлар чыгымнары классификациясе бюджетлары чыгымнары төрләре кодлары;

3000 – 3030 юллар буенча – керемне киметә торган салымнар түләү планлаштырыла торган бюджетлар керемнәре классификациясе бюджетлары керемнәренең ярдәмче төре аналитик төркеме кодлары (шул исәптән табышка салым, өстәлгән кыйммәткә салым, эшчәнлекнең аерым төрләре өчен билгеләнгән керемгә бердәм салым);

4000 – 4040 юллар буенча – бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары классификациясенең бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары төрләренең аналитик төркеме кодлары.

[4]4 графада Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2017 елның 29 ноябрендәге 209н номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясен куллану тәртибе нигезендә дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясе коды һәм (яки) башка аналитик күрсәткечләр кодлары (әгәр гамәлгә куючының Тәртибендә әлеге детальләштерү каралган булса) күрсәтелә.

[5]0001 һәм 0002 юллары буенча планлаштырыла торган елның башына һәм ахырына акчаның калган планлаштырыла торган суммалары күрсәтелә (әгәр әлеге күрсәткечләр гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган карары буенча План проектын төзү этабында планлаштырылса йә, хисап финанс елы тәмамланганнан соң, расланган Планга үзгәрешләр кертелгәндә акчаның фактта калган өлеше күрсәтелсә).

[6]Башка кертемнәр күрсәткечләрендә шул исәптән узган елларның дебитор бурычын кире кайтару (бирелгән заемнарны (микрозаемнарны) кире кайтаруны кертеп) хисабына, шулай ук банк депозитларында урнаштырылган акчаны кире кайтару хисабына акчаны арттыру күрсәткечләре дә бирелә. Бүлекчәгә План төзегәндә, башка кертемнәр күрсәткечендә баш учреждение белән бүлекчә арасындасы исәп-хисаплар кысаларында керемнәр күрсәткече бирелә.

[7]Планның «Кертемнәр һәм түләүләр» дигән 1 бүлеге юллары буенча чагылдырылган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр чыгымнары буенча түләү күрсәткечләре Планның «Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга түләүләр буенча белешмә» дигән 2 бүлегендә детальләштерелергә тиеш.

[8]Күрсәткеч «минус» билгесе белән чагылдырыла.

[9]Башка түләүләр күрсәткечләре шул исәптән агымдагы финанс елы башына кадәр бирелгән субсидияләр акчасын кире кайтару, заемнар (микрозаемнар) бирү,

автоном учреждениеләр тарафыннан банк депозитларында акча урнаштыру хисабына акча керемү күрсәткечләрен дә үз эченә ала. Бүлекчәгә План төзегәндә, башка кертемнәр күрсәткечендә баш учреждение белән бүлекчә арасындасы исәп-хисаплар кысаларында түләүләр күрсәткече бирелә.

[10]Планның «Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга түләүләр буенча белешмә» дигән 2 бүлегендә Планның «Кертемнәр һәм түләүләр» дигән 1 бүлегендәге тиешле юллар буенча чагылдырылган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу чыгымнары буенча түләүләр күрсәткечләре детальләштерелә.

[10.1]Әгәр федераль проектның, шул исәптән Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы белән билгеләнгән тиешле илкүләм проекты (программасы) составына керә торган федераль проектның яки федераль проектның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектының (алга таба – төбәк проекты) нәтиҗәләренә ирешү максатларында учреждениегә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 4 пунктының беренче абзацы нигезендә башка максатларга субсидия, капиталь салуларны гамәлгә ашыруга субсидия яки субсидия формасында грант бирелгән булса, «Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга түләүләр буенча белешмә» дигән 2 бүлекнең 26310, 26421, 26430 и 26451 юлларындагы күрсәткечләр максатчан статья коды буенча детальләштерелә (бюджетлар чыгымнары классификациясе кодының 8 – 17 разрядлары, шул ук вакытта төбәк проектын тормышка ашыру кысаларында 8 – 10 разрядта нульләр күрсәтелергә мөмкин).

[10.2]Әгәр капитал салуларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып федераль бюджет акчасы, шул исәптән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бюджетара трансферт рәвешендә бирелгән акча булса, «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасында бирелгән капиталь төзелеш объектының яки күчемсез мөлкәт объектының уникаль коды күрсәтелә.

[11]Планның «Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр ләр сатып алуга түләүләр буенча белешмә» дигән 2 бүлегендәге 26000 юл буенча товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга түләүләрнең план күрсәткечләре граждан законнары нигезендә төзелгән (төзергә планлаштырыла торган) контрактлар (шартнамәләр) буенча (26100 һәм 26200 юллар), шулай ук дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлар таләпләре нигезендә төзелә торган контрактлар (шартнамәләр) буенча түләүләргә бүленә, әлеге түләүләр агымдагы финанс елы башына кадәр төзелгән (26300 юл) һәм тиешле финанс елында төзергә планлаштырыла торган (26400 юл) контрактлар (шартнамәләр) буенча детальләштерелә.

[12]44-ФЗ номерлы Федераль законда һәм 223-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда, әлеге федераль законнар таләпләрен исәпкә алмыйча төзелгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар турындагы шартнамәләр (контрактлар) суммасы күрсәтелә.

[13]44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 223-ФЗ номерлы Федераль закон

нигезендә гамәлгә ашырыла торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар суммасы күрсәтелә.

[14]Дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан әлеге күрсәткеч формалаштырылмый.

[15]44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар суммасы күрсәтелә.